ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

05.08.2020 Балык Бистәсе штп. № 184пп

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) Нигезләмәсен раслау турында

Объектлар төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү максатларында федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә координация органнары (штаблар) булдыру мәсьәләсе буенча 2020 елның 30 гыйнварындагы җирле үзидарәне үстерү буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Совет утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 1 мартындагы Пр-354 номерлы йокләмәләре исемлегенең 1 пунктындагы 5 пунктчасын үтәү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М. В. Мишустинның 2020 елның 14 мартындагы ММ-П16-1825 номерлы күрсәтмәсенең 5 пунктын тормышка ашыру максатларында, шул исәптән милли проектларны, дәүләт һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) Нигезләмәсен;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) составын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның ___ ______________
_____ номерлы карары белән
расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Координация органының (штабларының) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча, шул исәптән милли проектларны, дәүләт һәм муниципаль программаларны тормышка ашыру кысаларында эшчәнлегенең максатларын, бурычларын, вәкаләтләрен һәм тәртибен билгели (алга таба – Штаб).

1.2.Штаб проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру кысаларында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен координацияләүне (яраштыруны) тәэмин итү максатларында дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, алар карамагындагы учреждениеләр һәм оешмалар, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлеккә ярдәм итүче коллегиаль киңәшләшү консультатив орган булып тора.

1.3. Штаб үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актларга, шулай ук штаб турындагы Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Штаб составына җирле үзидарә органнары, шулай ук табигый монополияләр субъектлары, ресурс белән тәэмин итү һәм челтәр оешмалары вәкилләре, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары, хокук саклау органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре (килешенү буенча) кертелә.

## 2. Штабның максатлары һәм бурычлары

1.5. Штаб булдыруның максаты – проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру кысаларында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм башка кызыксынган органнарның һәм оешмаларның килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү.

1.6. Штабның төп бурычлары булып консолидацияләнгән

(берләштерелгән) тәкъдимнәр әзерләү һәм түбәндәгеләр буенча карарлар кабул итү тора:

1.6.1. проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру кысаларында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган органнарның һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген һәм эшчәнлеген координацияләүне (яраштыруны) оештыру;

1.6.2. проектлар (программалар) максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чаралар планнарын эшләү;

1.6.3. проектларның (программаларның) максатларына һәм нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру срокларын законнар таләпләре нигезендә җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган органнар һәм оешмалар тарафыннан үтәүне тәэмин итү;

1.6.4. проектларны (программаларны) тормышка ашыру кысаларында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау срокларын озү куркынычы белән бәйле проблемаларны карау;

1.6.5. җирле үзидарә органнарына методологик яктан булышлык итү.

## 2. Штабның хокуклары

2.1. Штаб үз бурычлары нигезендә түбәндәгеләргә хокуклы:

2.1.1. федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнарыннан Штаб эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мәгълүмат соратып алырга;

2.1.2. Үз утырышларына кызыксынган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен, кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләрен чакырырга;

2.1.3. Штаб эшчәнлеге мәсьәләләре буенча дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар уздырган киңәшмәләрдә катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

2.1.4. Архитектура-төзелеш проектлау, инженерлык тикшеренүләре һәм капиталь төзелеш объектларын төзү өлкәсендә белгечләрне һәм экспертларны Штаб эшенә җәлеп итәргә (килешенү буенча).

## 3. Штабның эш тәртибе

3.1. Штаб штаб рәисе, штаб рәисе урынбасарлары, штабның җаваплы сәркатибе, шулай ук штаб әгъзалары составында төзелә.

3.2. Штаб рәисе булып тиңдәшле рәвештә муниципаль берәмлек башлыгы (алга таба – Рәис) тора.

3.3. Штаб Рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.3.1. Штаб эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

3.3.2. Штаб утырышларының датасы, урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында карар кабул итә;

3.3.3. Штаб утырышын алып бара;

3.3.4. Штаб утырышлары беркетмәләрен имзалый;

3.3.5. Штаб әгъзаларына тәкъдимнәр бирә;

3.3.6. Штаб составын үзгәртүгә башлангыч бирә;

3.3.7. Штаб кабул иткән карарларның тормышка ашырылуына гомуми контроль ясый.

3.4. Рәис булмаган чорда аның вазифаларын рәис йокләмәсе буенча Штаб рәисе урынбасары башкара.

3.5. Штабның җаваплы сәркатибе:

3.5.1. Штаб әгъзаларына Штаб утырышының датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, шул исәптән Штаб әгъзаларына Штаб утырышына документлар җибәрүне тәэмин итә;

3.5.2. Штаб утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә, аларны Штаб әгъзаларына җибәрә;

3.5.3. Штаб карарлары проектларын, башка документларны әзерли;

3.5.4. Штаб эшен тәэмин итү буенча башка төрле чараларны күрә.

3.6. Штаб әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

3.6.1. Штаб утырышында тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясарга һәм тәкъдимнәр кертергә;

3.6.2. Штаб эше кысаларында алынган мәгълүматны үз эшчәнлегендә кулланырга;

3.6.3. Штаб эшчәнлеге мәсьәләләре буенча карарлар проектларын эшләргә һәм фикер алышуга кертергә.

3.7. Штаб әгъзалары Штаб утырышында шәхсән үзләре катнаша. Штаб утырышына катнашу мөмкин булмаган очракта Штаб әгъзалары бу турыда Штабның җаваплы сәркатибенә хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Штаб утырышында катнашу мөмкинлеге булмаганда, Штаб әгъзасы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә җибәрергә хокуклы. Әлеге фикер Штаб утырышында каралырга тиеш, шулай ук Штаб утырышы беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

3.9. Штаб утырышлары зарурлык булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә..

3.10. Штабның чираттан тыш утырышларын уздыру мәсьәләсе Рәис яисә штаб әгъзалары карары буенча кузгатылырга мөмкин.

3.11. Штаб эше утырышлар, штаб әгъзаларының киңәшмәләре рәвешендә (шул исәптән аудио-һәм видеоэлемтә кулланып) оештырыла.

3.12. Штаб карарлары штаб рәисе кул куйган беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның ___ ______________
_____ номерлы карары белән
расланды

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны тәэмин итү буенча координация органы (штабы) составы

| | |
|---|---|
| Тажетдинов<br>Илдар Рәшит улы | Балык Бистәсе муниципаль район башлыгы, Штаб рәисе; |
| Исланов<br>Роман Леонидович | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе, Штаб рәисе урынбасары (килешенү буенча); |
| Ризаев<br>Дамир Наил улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, Штаб рәисе урынбасары (килешенү буенча); |
| Хәмидуллин<br>Ирек Мәсгут улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының ТА һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары, Штабның җаваплы сәркатибе (килешенү буенча). |

Штаб әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Хәсәнов<br>Рәүф Ногман улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының ТА һәм ТКХ бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Әсләмов<br>Хәлил Гарәфи улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Вафин<br>Фәрит Мансур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм милкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешенү буенча) |
| Мифтахов<br>Альберт Равил улы | Балык Бистәсе муниципаль районының "Теплоэнергосервис" муниципаль унитар предприятиесе директоры (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хәмидуллин Ринат Галинур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районында Приволжские электрические сети "Сетевая компания" ААЖ филиалы башлыгы (килешенү буенча) |
| Хәбибуллин Илнар Рафаэль улы | Балык Бистәсе РГЭСы "Сабыгаз" ЭПУ башлыгы (килешенү буенча) |
| Мостафин Наил Фоат улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |